Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Советы Карары

20 январь 2020 ел № 119

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында " 104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Күңгәр авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 104 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
**1.1.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
2.2. 0,12 процент Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары яки индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегеннән һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) ;
**1.2. 4.2 пунктта сүзтезмәне төшереп калдырырга**:
« яки шәхси эшмәкәрләр булган физик затлар»
**1.3.5 пунктны төшереп калдырырга .**
2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында:pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл башлыгы: Г.Х.Гарипова